Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Манзарас авыл башкарма комитеты

# КАРАР

2022 елның 08 нче сентябре №33

Манзарас авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге №47 номерлы карары белән расланган Манзарас авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Манзарас авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган Манзарас авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче пунктта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 12 нче пунктта:

а) икенче абзацта «, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүчеләрнең бирелгән ташламаларга ихтыяҗы, ул ташламаларга хокуклардан файдаланган түләүчеләр саны нисбәте һәм ташламаларны куллануга тулы хокукка ия булган түләүчеләр саны яки 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны белән характерлана.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе: Хәбибуллина Р.Г.